# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фондына кертемнәрнең 1995 елның беренче яртыеллыгына иминлек тарифы турында

<u>1 статья.</u> Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фондына кертемнәрнең 1995 елның беренче яртыеллыгына иминлек тарифын хезмәт өчен түләүнең һәрьяклап исәпләнелгән суммасына карата түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә:

милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр һәм башка хуҗалык субъектлары өчен - ике процент;

колхозлар һәм совхозлар өчен - бер процент.

<u>2 статья.</u> Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фондына иминлек кертемнәре түләүдән түбәндәгеләр азат ителәләр:

гарипләрнең җәмәгать оешмалары һәм дини берләшмәләр, шулай ук барлык табышларын әлеге оешмаларның һәм берләшмәләрнең устав максатларын гамәлгә ашыру өчен кулланучы алар милкендәге предприятиеләр, берләшмәләр һәм учреждениеләр;

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бюджетларыннан финансланучы хәрби частьләр, хәрби уку йортлары, Россия Федерациясенең Саклану министрлыгы предприятиеләре һәм оешмалары, Татарстан Республикасы Дәүләт иминлеге комитеты, Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы, аның хезмәт белән төзәтү учреждениеләре һәм төзелмә бүлекчәләре - гади һәм баш состав затларына түләнә торган акчалар һәм башка түләүләр суммасыннан.

3 статья. Күрсәтелгән акчаларны үз вакытында һәм тулысынча күчерүне тикшереп тору Татарстан Республикасының Дәүләт салым хезмәте һәм банк учреждениеләре белән берлектә Татарстан Республикасының Хезмәт һәм җәмгыяви мәсьәләләр буенча дәүләт комитетына йөкләнә.

4 статья. Әлеге Законны 1995 елның 1 гыйнвареннан гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1995 елның 18 гыйнваре
N 2309-XII